СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
**Татарстан Республикасы,422161**

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail:Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№ 1-40 «21» март 2019ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 03.03.2016 ел, 1-7 нче санлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 20 декабрендәге 106 –ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы , "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы" нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 03.03.2016 ел, 1-7 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 ел, № 2-14, 15.05.2017 ел, № 1-21, 14.11.2017 ел, № 2-26, 05.06.2018 ел, №2-32, 13.08.2018 ел, № 2-34, 20.11.2018 ел, № 3-37, 14.12.2018 №2-38 редакциядәге үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.8. 7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 7.4. пунктчасы белән тулыландырырга:

"7.4. Җитәкче булып эшләүче муниципаль хезмәткәр, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында муниципаль берәмлекнең әлеге җирле үзидарә органының һөнәр берлеге органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатен кайгырта алмый."

1.9. 8.1. пунктында:

" сәяси партия белән;" сүзләреннән соң "түләүсез нигездә һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан " сүзләре белән тулыландырырга.;

"бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылыр кооперативы," сүзләрен төшереп калдырырга;

"сәяси партиядән башка" сүзләреннән соң һәм һөнәр берлеге органыннан шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башлыгы Р.К.Хафизовка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Р.К.Хафизов

СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ИШКЕЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1626001690